КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен мәгариф оешмаларын матди-техник база белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 19 декабрь, 1158 нче карары белән расланган 2021 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен мәгариф оешмаларын матди-техник база белән тәэмин итү буенча чаралар комплексына («юл картасына») үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен мәгариф оешмаларын матди-техник база белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 19 декабрь, 1158 нче карары белән расланган 2021 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен мәгариф оешмаларын матди-техник база белән тәэмин итү буенча чаралар комплексына («юл картасына»), аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 декабрь, 1158 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 декабрь, 1287 нче
карары редакциясендә)

2021 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының
«Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында
цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен мәгариф оешмаларын
матди-техник база белән тәэмин итү буенча
чаралар комплексы («юл картасы»)

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручы | Нәтиҗәсе | Срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 2021 ел | | | | |
| 1. | 2021 һәм 2022 елларда төбәк ведомство проект офисы составындагы цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җаваплы вазыйфаи затны раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2020 елның 30 ноябре |
| 2. | 2021 елда Татарстан Республикасында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү планын раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2020 елның 30 ноябре |
| 3. | 2021 һәм 2022 елларда цифрлы белем бирү мохите гамәлгә кертеләчәк мәгариф оешмалары исемлеген раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2020 елның 30 ноябре |
| 4. | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган җиһазларның якынча исемлеге нигезендә 2021 елда цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җиһазлар исемлеген билгеләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2020 елның 30 ноябре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5. | «Электрон бюджет» ижтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү турында килешү төзү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Субсидия бирү турында килешү | 2020 елның 30 ноябре алга таба – кирәк булуга карап |
| 6. | 2021 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү буенча товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны игълан итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Сатып алуларны үткәрү турында хәбәрнамәләр | 2021 елның 1 марты |
| 7. | 2021 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен сатып алынган җиһазның 2021 елда Татарстан Республикасында цифрлы белем бирү мохитен гамлгә кертү планы максатларына һәм бурычларына туры килүкилмәвенә мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки федераль оператор тарафыннан билгеләнә торган форма буенча | 2021 елның 25 августы, алга таба – ел саен |
| 2022 ел | | | | |
| 1. | 2022 елларда төбәк ведомство проект офисы составындагы цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җаваплы вазыйфаи затны раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы (кирәк булганда 2020 елгы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән | 2021 елның декабре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү) | |
| 2. | 2022 елда цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү чараларын тормышка ашыруда катнашучы мәгариф оешмалары исемлеген раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы адресына мәгариф оешмалары исемлеге теркәлгән хаты; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы (кирәк булганда 2020 елгы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү) | 2021 елның декабре |
| 3. | 2022 елда цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җиһаз, чыгым материалларын, уку-укыту һәм тәрбия бирү чаралары исемлеген формалаштыру һәм раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы адресына цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җиһаз, чыгым материалларын, уку-укыту һәм тәрбия бирү чаралары исемлеге теркәлгән хаты; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән | «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисының аерым графигы нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | министрлыгының цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җиһаз, чыгым материаллары, уку-укыту һәм тәрбия бирү чаралары исемлеген раслау турында боерыгы | |
| 4. | 2022 елда цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен җиһаз сатып алуларны игълан итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Сатып алуларны үткәрү турында хәбәрнамәләр яки хәбәрнамәләр реестры («Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы формасы буенча) | 2022 елның 15 феврале |
| 5. | Җиһаз сатып алу, аны кайтарту һәм көйләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Игълан ителгән сатып алулар кысаларында матди кыйммәтләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне кабул итүне раслый торган документлар реестры | 2021 елның 25 августы |
| 6. | 2022 елда методик тәкъдимнамәләр нигезендә цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү чараларын тормышка ашыру барышына мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки «Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы тарафыннан билгеләнгән форма буенча | 2022 елның 1 апреле; 2022 елның 1 июне; 2022 елның 25 августы; 2022 елның 30 ноябре |

___________________________